ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

4 октябрь, 2019 ел. Казан шәһәре № 297

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 05 февралендәге 29 номерлы боерыгы белән расланган Товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) бәяләрне (тарифларны, өстәлмәләрне, арттыруларны) куллануның дөрес һәм аларның зурлыкларының нигезле булуы өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын үтәү буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында
б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 05 февралендәге 29 номерлы боерыгы белән расланган Товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) бәяләрне (тарифларны, өстәлмәләрне, арттыруларны) куллануның дөрес һәм аларның зурлыкларының нигезле булуы өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын үтәү буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты административ регламентына (Дәүләт комитетының 09.03.2016 № 50, 31.01.2017 № 16, 07.08.2017 № 190, 28.09.2018 № 266, 14.12.2018 № 425 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.7.2 пунктның 16 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.8.1 пунктның 9 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2.3.1 пунктның 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең бер резидентына карата тикшерү уздырганда, тикшерүне уздыручы Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының нигезле тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озак вакытлы махсус тикшеренүләрне һәм экспертизаларны уздыру зарурлыгына бәйле искәрмәле очракларда, тикшерү уздыру срогы озынайтыла, ләкин кече предприятиеләргә карата – иң күбе утыз сәгатькә һәм микропредприятиеләргә карата – иң күбе ун сәгатькә һәм алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең башка резидентларына карата – иң күбе унбиш эш көненә.»;

2.4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2019 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәрге чорда үзләре турында белешмәләр кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясына ярашлы нигездә кече эшкуарлык субъектларына кертелгән юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр 294-ФЗ номерлы Федераль законның 26.2 статьясындагы таләпләргә ярашлы рәвештә оештырыла һәм үткәрелә.»;

3 бүлектә:

3.3 пунктта «юридик зат, шәхси эшкуар элегрәк тиешле таләпләрне бозган өчен җаваплылыкка тартылмаган очракларда» сүзләрен төшереп калдырырга;

1нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| № п/п | Зарури таләпләр белдерелә торган эшчәнлек төрләре | Зарури таләпнең тәгъбирләнеше | Зарури таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләре (тарифлары) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан билгеләнә торган товарларны сату, хезмәтләр күрсәтү | Җайга салынулы бәяләрне куллануның дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законның 5, 7 статьялары;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары;<br>әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 2. | Электр энергетикасы | Җайга салынулы | «Электр энергетикасы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | өлкәсендә бәяләре (тарифлары) законнарда билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган товарларны сату, хезмәтләр күрсәтү | бәяләрне билгеләүнең, бәяләрне куллануның дөреслеге һәм аларның күләменең нигезләнгән булуы | турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясының 4 өлеше, 24 статьясының 3 өлеше;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары»;<br>әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 3. | Эшкуарлык (һөнәри) эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле булмаган шәхси, гаилә, йорт һәм башка ихтыяҗларны (автотранспорт чараларын тәэмин итү өчен газдан тыш) канәгатьләндерү өчен халыкка газ сату;<br>көнкүреш ихтыяҗлары өчен халыкка сыекландырылган газ сату, эшкуарлык (һөнәри) эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле булмаган, автотранспорт чараларын газ белән тәэмин итү өчен газ сатудан тыш;<br>газ кулланучы җиһазларны газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтыру буенча хезмәт күрсәтү | Җайга салынулы бәяләрне куллануның дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 29 декабрендәге 1021 номерлы карары белән расланган Газга бәяләрен, аны транспортлау хезмәте күрсәтүгә тарифларны һәм газ кулланучы җайланмаларны газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтыруга түләүне формалаштыру һәм дәүләти җайга салу буенча төп нигезләмәләрнең 8 пункты;<br>әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | Гражданнарга, идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки башка, гражданнарның торакка ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында оештырылган махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына каты ягулык, көнкүреш өчен мич ягулыгы һәм керосин сату | Җайга салынулы бәяләрне куллануның дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары;<br>әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 5. | Шәһәр юнәлешендә (автомобиль транспортыннан һәм җир өсте шәһәр электр транспортыннан тыш) һәм шәһәр яны билгеләнешендә (тимер юл транспортыннан, автомобиль транспортыннан һәм җир өсте шәһәр электр транспортыннан тыш) гомуми файдаланудагы транспортларның барлык төрләрендә пассажирлар һәм багаж ташу | Җайга салынулы бәяләрне куллануның дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары;<br>әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 6. | Федераль законнарда билгеләнгән очракларда пассажирларны һәм багажны автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында ташу. | Җайга салынулы бәяләрне куллануның дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары;<br>әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | комитеты актлары |
| 7. | Шәһәр яны тимер юл транспортында пассажирлар һәм багаж ташу | Җайга салынулы бәяләрне куллануның дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 2.1 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә салу чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары;<br>әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 8. | Җирле билгеләнештә һәм кичүләрдә җирле авиалинияләрдә һәм елга транспортында пассажирлар һәм багаж ташу | Җайга салынулы бәяләрне куллануның дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары;<br>әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 9. | Сәнәгый тимер юл транспорты оешмалары һәм оешу-хокук йормасына бәйсез рәвештә башка хуҗалык итүче субъектлар тарафыннан тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләре, федераль тимер юл транспорты оешмаларыннан тыш | Җайга салынулы бәяләрне куллануның дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары;<br>әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10. | Гомер өчен кирәкле һәм әһәмиятле дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларын күпләп сәүдә итүче оешмалар, даруханә оешмалары, фармацевтика эшчәнлегенә лицензиясе булган шәхси эшкуарлар тарафыннан сату | Җайга салынулы бәяләрне куллануның дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | «Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары;<br>әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 11. | Су белән тәэмин итү, агынты суларны агызу өлкәсендә бәяләре (тарифлары) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан билгеләнә торган товарларны сату, хезмәтләр күрсәтү | Җайга салынулы бәяләрне куллануның дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | «Су белән тәэмин итү һәм агынты суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясы;<br>«Су белән тәэмин итү һәм агынты суларны агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары;<br>әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 12. | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәяләре (тарифлары) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнә торган хезмәтләрне күрсәтү | Җайга салынулы бәяләрне куллануның дөреслеге һәм бәя билгеләү тәртибе таләпләренең үтәлеше. | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законның 24.9 статьясындагы 9 өлеше, 24.12 статьясындагы 5 өлеше;<br>Россия Федерациясе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары;<br>әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 13. | Гражданнарга дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган социаль хезмәтләр | Җайга салынулы бәяләрне кулланунаның дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары;<br>«Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне финанслауның җан башына исәпләнгән нормативлары нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә тарифларны раслау тәртибен раслау турында» 2014 елның 18 декабрендәге 999 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;<br>әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 14. | Гомуми белем мәктәпләре, һөнәри техник училищелар, урта махсус һәм югары уку йортлары каршындагы җәмәгать туклануы предприятиеләрендә продукция (товарлар) сату | Җайга салынулы бәяләрне кулланунаның дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары;<br>әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 15. | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан челтәр оешмаларының электр челтәрләренә технологик тоташтыру буенча хезмәт күрсәтү | Технологик тоташтыруга түләүне һәм (яки) әлеге түләү күләмен билгели торган стандартлаштырылган тариф ставкаларын территориаль челтәр оешмалары тарафыннан куллануның дөреслеге | «Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясындагы 3 өлеше;<br>әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 16. | Татарстан Республикасы территориясендә торак фондын техник инвентаризацияләү | Җайга салынулы бәяләрне куллануның дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1997 елның 13 октябрендәге 1301 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә Торак фондын дәүләт исәбенә алу турындагы нигезләмәнең 8 пункты;<br>әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 17. | Тоткарланган транспорт чарасын саклау | Җайга салынулы бәяләрне куллануның дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | «Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерү, аларны саклау, кире кайтару, бер урыннан икенче урынга күчергән һәм саклаган өчен чыгымнарны түләү тәртибе турында» 2012 елның 17 маендагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы;<br>әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | комитеты актлары |
| 18. | Тракторларның, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка машиналарның һәм аларга тагылмаларның техник торышына дәүләт күзәтчелеген уздырганда хезмәт күрсәтү | Җайга салынулы бәяләрне куллануның дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1993 елның 13 декабрендәге 1291 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмәнең 6 пункты; әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 19. | Транспорт чараларына дәүләт техник карау үткәрү, диагностик карта дубликатын бирү | Җайга салынулы бәяләрне куллануның дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | «Транспорт чараларын техник карау һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 1 июлендәге 170-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, 19 статьясындагы 9 өлеше; әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 20. | Татарстан Республикасы мөлкәтендәге су объектларын файдалануга бирү | Җайга салынулы бәяләрне куллануның дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | Россия Федерациясе Су кодексының 25 статьясы; әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 21. | Татарстан Республикасы мөлкәтендәге урман ресурсларын яисә урман кишәрлеген аренда максатларында бирү | Җайга салынулы бәяләрне куллануның дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | Россия Федерациясе Урман кодексының 82 статьясы; әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 22. | Татарстан Республикасы | Җайга салынулы | Россия Федерациясе Урман |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | мөлкәтендәге җирләрдә әзерләнә торган агач материалын бирү | бәяләрне кулланунын дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | кодексының 82 статьясы; әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 23. | Гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмалары сату | Җайга салынулы бәяләрне кулланунын дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | Россия Федерациясе Урман кодексының 82 статьясы; әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |
| 24. | Кадастр эшләрен башкару | Җайга салынулы бәяләрне кулланунын дөреслеге һәм аларның зурлыгының нигезлелеге | «Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль Законның 47 статьясы; әлеге эшчәнлек өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) билгели торган Дәүләт комитеты актлары |

;»

4 бүлектәге 2нче таблицаның 2.4 пунктындагы 3нче графада «2017 елның 1 сентябрендәге 566 номерлы Росстат боерыгы» сүзләрен «2019 елның 15 июлендәге 404 номерлы Росстат боерыгы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Л.П. Борисовка йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром